**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында» 2018 елның 3 маендагы ПУ-346 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 24 гыйнварындагы ПУ-21 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге ПУ-71 номерлы, 2022 елның 8 октябрендәге ПУ-724 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 маендагы 330 номерлы һәм 2024 елның 27 февралендәге 151 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составына (алга таба – Комиссия) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан М.Ю. Застеланы, Й.М. Кәшапованы, Д.С. Романовны, К.Г. Садриевны, В.С. Саттаровны, А.М. Фроловны чыгарырга;

б) Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Галиева Эльвира Рәкыйп кызын – Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасы баш дәүләт торак инспекторы урынбасарын;

Гәрәева Эльвира Марат кызын – Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең хокук идарәсе юридик бүлеге башлыгын;

Егоров Андрей Юрьевичны – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисен (килешү буенча);

Комисаров Александр Владимировичны – «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлекчәсе вәкилен (килешү буенча);

Хисмәтуллин Минәхмәт Хаҗи улын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасын (килешү буенча);

Шәйдуллин Дамир Фәрит улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасарын.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 28 декабрь
№ 1034